**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ СТЕПНООЗЕРСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БИКҮЛЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

№ 11 «23»июнь 2021 ел

«2021-2024 елларга Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Бикүле авыл җирлегендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү» муниципаль программасын раслау турында

Нурлат муниципаль районының Бикүле авыл җирлеге территориясендә кече һәм урта эшкуарлык субъектлары тарафыннан эшкуарлык эшчәнлеген алып бару өчен уңайлы икътисадый мохит булдыру һәм кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү максатларында, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 2010 елның 21 гыйнварындагы 7-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Нурлат муниципаль районының Бикүле авыл җирлеге Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Әлеге карарга кушымта нигезендә «2021-2024 елларга Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Бикүле авыл җирлегендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү» муниципаль программасын расларга.
2. Әлеге карарны Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында http://nurlat.tatarstan.ru/ бастырып чыгарырга һәм җирлек территориясендәге мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Бикүле авыл җирлеге
Башкарма комитеты җитәкчесе А.М.Шакирова

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Бикүле авыл җирлеге Башкарма комитетының 2021 елның 23 июнендәге 11 номерлы карарына кушымта

# «2021-2024 ЕЛЛАРГА ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БИКҮЛЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕНДӘ КЕЧЕ ҺӘМ УРТА ЭШКУАРЛЫКНЫ ҮСТЕРҮ» ПРОГРАММАСЫ

2021 ел

Эчтәлек

Программаның Паспорты

1. Программаны гамәлгә ашыру өлкәсе характеристикасы. Программа хәл итүгә юнәлдерелгән проблемалар аларны хәл итү юллары

2. Программаның көтелгән төп нәтиҗәләренең максаты, бурычлары, тасвирламасы, аны гамәлгә ашыру сроклары һәм этаплары

3. Программаны гамәлгә ашыру механизмы

4.Программаның социаль-икътисадый нәтиҗәлелеген бәяләү

«2021-2024 елларга Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Бикүле авыл җирлегендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү» программасы паспорты

| | |
|---|---|
| Программаның исеме | «2021-2024 елларга Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Бикүле авыл җирлегендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү» программасы (алга таба - Программа) |
| Программа әзерләү өчен нигез | «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 2010 елның 21 гыйнварындагы 7-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы |
| Программаны эшләүче | Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Бикүле авыл җирлеге башкарма комитеты |
| Программаны финанслау күләмнәре һәм чыганаклары | Нурлат муниципаль районы халкын эш белән тәэмин итү программалары.<br>Кредит акчалары һәм эшкуарларның үз акчалары.<br>Җирле бюджет чаралары хисабына финанслау |
| Программаның максаты | Кече һәм урта эшкуарлык субъектларын үстерү өчен уңайлы шартлар булдыру, инновацион икътисадны формалаштыруның мөһим компоненты буларак кече һәм урта эшкуарлык субъектларының санын арттыру һәм көндәшлеккә сәләтлелеген тәэмин итү, шулай ук аның җирлекнең социаль-икътисадый үсеше мәсьәләләрен хәл итүгә керткән өлешен арттыру. |

| | |
|---|---|
| Программаның бурычлары | 1. Җирлектә кече хуҗалыкларны тотрыклы үстерү өчен шартлар тудыру;<br>2. Эшкуарлыкның кадрлар потенциалын үстерү;<br>3. Кече һәм урта эшкуарлык субъектларын консультация белән тәэмин итү сыйфатын арттыру;<br>4. Эшкуарлык эшчәнлегенә икътисадый яктан актив халыкны җәлеп итү. |
| Гамәлгә ашыру сроклары һәм | 2021-2024 еллар |
| Программаны үтәүчеләр | Кече, урта эшкуарлык субъектлары һәм үзләре эшли торган җирлекләр,<br>Нурлат муниципаль районының Бикүле авыл җирлеге Башкарма комитеты |

| | |
|---|---|
| Программаның максатларын һәм бурычларын гамәлгә ашыруның көтелә торган ахыргы нәтиҗәләре | Программа чараларын тулы күләмдә гамәлгә ашыру 2024 ел ахырына ирешергә мөмкинлек бирәчәк:<br>- кече предприятиеләр, шул исәптән микропредприятиеләр һәм индивидуаль эшкуарлар җитештерә торган продукция (хезмәт күрсәтүләр) әйләнешенең еллык үсешен саклап калу;<br>- җирлек территориясендә эшчәнлек алып баручы кече һәм урта эшкуарлык субъектлары (шул исәптән үз-үзләрен тәэмин итүчеләр) санының еллык үсешен саклап калу;<br>- барлык предприятиеләрнең уртача исемлек санында кече (микропредприятиеләрне дә кертеп) һәм урта предприятиеләрдә хезмәткәрләрнең (тышкы бергә эшләүчеләрдән башка) урта исемлек саны өлешен арттыру;<br>- кече һәм урта эшкуарлык субъектларына консультация ярдәме күрсәтү;<br>- кече һәм урта эшкуарлык секторында яңа эш урыннары (яңа теркәлгән индивидуаль эшкуарларны да кертеп) булдыру;<br>Шул ук вакытта Программа чараларын үтәү кече һәм урта эшкуарлык инфраструктурасының уңышлы эшләве, кече һәм урта эшкуарлык өлкәсендә товар (эшләр, хезмәт күрсәтүләр) җитештерү күләмнәрен арттыру, шулай ук аларның эшчәнлегеннән салым керүне авыл җирлеге бюджетына арттыру өчен шартлар тудыруны күздә тота. |

Программаны гамәлгә ашыру өлкәсенә характеристика.
Программа хәл итүгә юнәлтелгән проблемалар хәл итү юллары.

2020 елда Нурлат муниципаль районының Бикүле авыл җирлегендә салым органында теркәлгән 5 шәхси эшмәкәр, шулай ук 14 үзмәшгульлек алып баручы (2019 елга караганда 2гә күбрәк) үз эшчәнлеген башкарды.

Таблица 1

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Бикүле авыл җирлегендә эшкуарлык өлкәсен үстерүнең төп тенденцияләре

| Күрсәткечләр | 2018 ел (факт) | 2019 ел (факт) | 2020 ел (бәяләү) |
|---|---|---|---|
| Икътисадый актив эшмәкәрлек субъектлары саны: | 4 | 17 | 19 |
| кече предприятиеләр, бер. | | | |
| төп дәүләт теркәү номеры булган (теркәлүне узган) индивидуаль эшкуарлар - барлыгы, бер. | 4 | 5 | 5 |
| үзмәшгуль, бер. | - | 12 | 14 |

Таблица 2

Икътисадый эшчәнлек төрләре буенча кече һәм урта эшкуарлык субъектлары саны

| Эшчәнлек төрләре | Күрсәткеч берәмлеге. | фактагы күрсәткеч |
|---|---|---|
| | | 01.01.2021 |
| Кече эшкуарлыкның исәпкә алынган барлык икътисадый актив субъектлары | бер. | 19 |
| шулардан икътисадый эшчәнлек төрләре буенча: авыл хуҗалыгы, аучылык һәм | бер. | 2 |
| Балык тоту, балык үрчетү | бер. | 0 |
| Файдалы казылмалар чыгару | бер. | 0 |
| Эшкәртү производстволары | бер. | 0 |
| Электр энергиясен, газны һәм суны | бер. | 0 |
| Төзелеш | бер. | 0 |
| Күпләп һәм ваклап сату; автотранспорт | бер. | 3 |
| Кунакханә һәм рестораннар | бер. | 0 |
| Транспорт һәм элемтә | бер. | 0 |
| Финанс эшчәнлеге | бер. | 0 |
| Күчемсез милек, аренда һәм хезмәтләр | бер. | 0 |
| Дәүләт идарәсе һәм хәрби | бер. | 0 |
| Белем бирү | бер. | 0 |
| Сәламәтлек саклау һәм социаль хезмәтләр | бер. | 0 |
| Башка коммуналь, социаль һәм шәхси | бер. | 0 |
| Йорт хуҗалыгын алып бару буенча | бер. | 0 |
| Экстерриториаль оешмалар эшчәнлеге | бер. | 0 |
| Башкалар | бер. | 14 |

Төп күрсәткечләргә анализ районда кече һәм урта эшкуарлык өлкәсен үстерүнең уңай динамикасы турында сөйли.

2020 елда эшкуарлыкка ярдәм итүнең иң популяр программалары «Агростартап» программалары, Татарстан Республикасы Эшкуарлыкка ярдәм фонды микрозаймнары булды.

Кече эшкуарлыкка мәгълүмати ярдәм күрсәтү һәм үз бизнесын булдыруны популярлаштыру буенча актив кампания кысаларында, аның максаты-җитештерү һәм хезмәт күрсәтү өлкәсендә эшләүче, эчке һәм тышкы базарларда конкурентлыкка сәләтле кече һәм урта предприятиеләр санының тотрыклы үсешен тәэмин итү: барлык мәгълүмат Нурлат муниципаль районының рәсми порталына урнаштырылды, шулай ук даими рәвештә эшкуарлык эшчәнлеген алып баруның аерым мәсьәләләренә һәм әлеге өлкәдә актуаль мәсьәләләр турында фикер алышуга, шулай ук аны алга таба үстерүнең уртак чараларын эшләүгә юнәлдерелгән киңәшмәләр, конференцияләр, форумнар, утырышлар уздырылды.

Кызыксынган оешмалар белән берлектә кече һәм урта эшкуарлык субъектларына кече һәм урта эшкуарлыкка гамәлдәге дәүләт ярдәме чаралары, үзмәшгульләргә, шулай ук Эшкуарлык өлкәсендәге законнардагы үзгәрешләр турында хәбәр итүгә юнәлдерелгән чаралар даими үткәрелде.

## 2. Программаның максаты, бурычлары, төп көтелгән ахыргы нәтиҗәләрен тасвирлау, аны тормышка ашыру вакыты һәм этаплары

Кече һәм урта эшкуарлыкка ярдәм итү һәм аны үстерү өлкәсендәге эш юнәлеше эшкуарлык субъектларының эшлекле активлыгын үстерү өчен уңай климат булдыруга, эшкуарлык үсешенә төп чикләүләрнең йогынтысын киметүгә юнәлдерелгән һәм Нурлат муниципаль районының Бикүле авыл җирлеге үсешенең стратегик максатлары, бурычлары һәм приоритетлары системасына Эшкуарлыкка ярдәм итү юнәлешләрен булдыруга нигезләнгән.

Әлеге максат белән урта сроклы перспективага социаль-икътисадый үсешнең төп бурычлары билгеләнә һәм әлеге бурычлар кысаларында кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм итү чараларын гамәлгә ашыруга тәкъдим ителә.

Авыл җирлегендә эшмәкәрлек үсешен тоткарлый торган, әлеге сораштыруларга һәм эшкуарлык җәмәгатьчелеген анкеталаштыруга нигезләнгән төп проблемалар булып тора:

- кадрлар кытлыгы;
- кече һәм урта бизнес өчен салым йөкләнеше дәрәҗәсе югары;
- финанс ресурсларыннан файдалану түбән дәрәҗәдә;
- Җир һәм күчемсез мөлкәтнең һәркем файдалана алырлык булуы;
- энергетика инфраструктурасының һәркем файдалана алырлык булуы;
- яңа җиһазлар сатып алу белән бәйле проблемалар.

Программаның максаты - кече һәм урта эшкуарлык субъектлары үсеше өчен уңай шартлар тудыру, инновацион икътисад формалаштыруның мөһим компоненты буларак кече һәм урта эшкуарлык субъектларының санын арттыру һәм аларның конкурентлык сәләтен тәэмин итү, шулай ук аның районның социаль-икътисадый үсеше бурычларын хәл итүгә керткән өлешен арттыру.

Әлеге максатка ирешү өчен түбәндәге бурычларны хәл итәргә кирәк:

1. Җирлектә кече хуҗалыкларны тотрыклы үстерү өчен шартлар тудыру;
2. Эшкуарлыкның кадрлар потенциалын үстерү;
3. Кече һәм урта эшкуарлык субъектларын консультация белән тәэмин итү сыйфатын арттыру;
4. Эшкуарлык эшчәнлегенә икътисадый яктан актив халыкны җәлеп итү.

Программаның төп чаралары Программаның максатларыннан һәм бурычларыннан чыгып формалаштырылды.

Шул ук вакытта һәр бурычны хәл итү кысаларында, шул исәптән, яңа эш урыннары булдыруны күздә тоткан кече һәм урта эшмәкәрлек

субъектларын, аларның санын арттыру өлешендә һәм бизнесны үстерү өлешендә ярдәм итүгә һәм үстерүгә юнәлтелгән чаралар каралган.

## Программаның төп чараларына характеристика

Гомумән алганда, кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм итү чараларын 2 төп юнәлешкә бүлеп була:

1. Кече һәм урта эшкуарлык субъектларына консультация ярдәме күрсәтү чаралары;
2. Эшкуарлыкны үстерү буенча башка чаралар.

Эшмәкәрләргә консультация ярдәме күрсәтү юнәлешләре кысаларында түбәндәге чаралар каралачак:

1. Республика һәм федераль бюджетлар акчаларыннан эшмәкәрлеккә ярдәм итү программалары буенча консультация ярдәме күрсәтү һәм мәгълүмат бирү;

Эшкуарлыкны үстерү буенча башка чаралар:

1. кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү проблемалары буенча анкета үткәрү һәм аларны хәл итү юллары;
2. эшкуарлыкка ярдәмнең гамәлдәге программалары буенча законнарны үзгәртүгә һәм үстерүгә бәйле актуаль хокукый мәсьәләләр буенча кече һәм урта эшкуарлык субъектлары өчен киңәшмәләр һәм семинарлар уздыру;
3. кече һәм урта эшкуарлык субъектларына мәгълүмати ярдәм күрсәтү кампаниясен оештыру һәм үз бизнесын булдыруны популярлаштыру, шул исәптән яшьләр бергәлеге арасында.

Максатлар һәм бурычлар киселешендә төп чаралар исемлеге Программага кушымтада бирелгән.

## Программаны гамәлгә ашыру сроклары һәм этаплары

Программа 2021 елдан 2024 елга кадәр гамәлгә ашырыла.

## 3. Программаны гамәлгә ашыру механизмы

Программаны гамәлгә ашыру белән идарә итүне Нурлат муниципаль районының Бикүле авыл җирлеге башкарма комитеты гамәлгә ашыра:

- Программа чараларын гамәлгә ашыруны планлаштыруны, үзара хезмәттәшлекне, координацияне һәм тикшереп торуны оештыра;
- программа чаралары исемлеген, максатчан индикаторларны һәм Программаның нәтиҗәлелеге күрсәткечләрен әзерләүне һәм төгәлләштерүне гамәлгә ашыра.

Программаны гамәлгә ашырганда Нурлат муниципаль районының Бикүле авыл җирлеге башкарма комитеты чараларны үтәүчеләр белән

хезмәттәшлек итә. Программа чараларын үтәүчеләр программа чараларын вакытында һәм сыйфатлы үтәгән өчен җаваплы.

## 4. Программаның социаль-икътисадый нәтиҗәлелеген бәяләү

Программаны гамәлгә ашыру ярдәм итәчәк:

- Эчке һәм тышкы базарларда кече һәм урта эшкуарлык субъектларының конкурентлык сәләтен арттырырга;
- яңа эшләнмәләрне стимуллаштырырга һәм яңа технологияләрне үзләштерүгә ярдәм итәргә;
- кече һәм урта эшкуарлык субъектларында мәгълүмати технологияләр куллануны киңәйтергә;
- Эшкуарлык эшчәнлеге белән кызыксынуны арттыру исәбенә халыкның эшлекле активлыгын үстерергә;
- - кече һәм урта эшкуарлык субъектларының финанс һәм матди ресурсларга керүен тәэмин итүче механизмнарны камилләштерергә;
- - кече һәм урта эшкуарлык субъектларына мәгълүмати-консультация ярдәмен камилләштерү;
- кече һәм урта эшкуарлык субъектларын дәүләт һәм муниципаль заказларны үтәүгә җәлеп итәргә.

Кушымта

«2021-2024 елларга Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Бикүле авыл җирлегендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү» программасы нәтиҗәләрен бәяләүнең максатлары һәм индикаторлары

| Төп чаралар аталышы | Бурычка тәңгәл килү | Башкаручылар | Төп чараларны башкару сроклары | Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары, үлчәү берәмлекләре | Индикаторларның күрсәткечләре | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | 2021 ел | 2022 ел | 2023 ел | 2024 ел |
| Максат исеме: кече һәм урта эшкуарлык субъектлары үсеше өчен уңай шартлар тәэмин итү, инновацион икътисад формалаштыруның мөһим компоненты буларак кече һәм урта эшкуарлык субъектларының санын арттыру һәм аларның конкурентлык сәләтен тәэмин итү, шулай ук җирлекне социаль-икътисадый үстерү бурычларын хәл итүгә аның кертемен арттыру | | | | | | | | |
| Республика һәм федераль бюджетлар акчаларыннан эшмәкәрлеккә ярдәм итү программалары буенча консультация ярдәме күрсәтү һәм мәгълүмат бирү | 3 | Нурлат муниципаль районы Бикүле авыл җирлеге Башкарма комитеты | 2021-2024 | Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына күрсәтелгән консультацияләр саны бер. | 1 | 1 | 1 | 1 |
| Кече эшмәкәрлекне үстерү проблемаларына анкета үткәрү кече һәм урта эшмәкәрлек аларны хәл итү юллары | 4 | Нурлат муниципаль районы Бикүле авыл җирлеге Башкарма комитеты | 2021-2024 | Үткәрелгән анкеталар, берәмлекләр саны | 1 | 1 | 1 | 1 |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Кече һәм урта эшкуарлык субъектлары өчен актуаль хокукый мәсьәләләр буенча киңәшмәләр һәм семинарлар үткәрү Законнарны үзгәртү һәм үстерү, шулай ук гамәлдәге программалар буенча | 1 | Нурлат муниципаль районы Бикүле авыл җирлеге Башкарма комитеты | 2021-2024 | Үткәрелгән семинарлар саны, бер. | 1 | 1 | 1 | 1 |
| Яшьләр эшкуарлыгы өлкәсенә җәлеп итү буенча яшьләр бергәлеге белән эшләү | 2 | Нурлат муниципаль районы Бикүле авыл җирлеге Башкарма комитеты | 2021-2024 | Үткәрелгән семинарлар саны, бер. | 1 | 1 | 1 | 1 |